## СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ГЕРОЙЛАРЫ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР

### 15 нче февраль – интернационал бурычларын туган илдән читтә башкарган ватандашларыбызны искә алу көне

### Зиннур Галиев

Урта мәктәпне тәмамлаганда Зиннур ага үзенең тормышында зур борылышлар буласын күз алдына да китермәгәндер. Актаныштa шоферлар әзерләү курсын тәмамлау белән егет армия сафларына алына. Ерак Көнчыгышка озатылган Түбән Табын авылы егете кече командирлар әзерләү мәктәбендә биш ай укый һәм сержант дәрәҗәсен ала. Чик сакчысы булуына сөенә. Ерак Көнчыгышның 40-50 градус салкыннарына да түзә солдат. Ләкин барысы да алда булган икән әле. Учебкадан соң аларны Урта Азиягә озаталар, 1984 нче елның 11 маенда алар Әфганстанга керәләр. Зиннур абыебыз "Кайсар" мототөркеменә БТР командиры итеп билгеләнә. Ачлык, югалтулар һәм сусызлык белән тоташкан көннәрнең азагы булмас кебек тоелган вакытларда ул, якыннарын уйлап, җанына тынычлык ала. Десант штурм төркемендә дә хезмәт итә Зиннур абый. Снайпер да, гранотометчы да, пулеметчы да булырга туры килә. Бервакыт, көтмәгәндә, ул үзенең иптәшләре белән чолганышта кала. Шундый куркыныч астында да ул хезмәттәшләрен чолганыштан алып чыга ала. Әлеге тәвәккәллеге өчен ул "Батырлык өчен" медаленә лаек була.

- Зиннурыбызның Әфганстанда булуын белмәдек. Без борчылмасын дип әйтеп тә тормаган, балакаем. "Ярый әле безнеке анда әләкмәде", дип өйдә сөенеп ятканда Зиннур шул мәхшәрнең үзәгендә кайнаган. Армиядән әйләнеп кайтырына бер ай калганда, очраклы рәвештә генә белдек. Олы йөрәкле, ата-ана җанлы дими, тагын нәрсә дисең?! Шул вакытларда да безне уйлаган бит ул! - ди әнисе, улы белән горурланып. Зиннур Галиев Әфганстаннан 1985 нче елның 19 нчы декабрендә чыга. Зиннур абый ул еллар турында иркенләп сөйләргә яратмый. Интернециональ бурычларын үтәгәндә комлы-ташлы далаларда ятып калган дусларын искә алганда, Зиннур абый аеруча дулкынлана. Күпме еллар үтсә дә, авыр хатирәләр аның йөрәгендә яңара, яралы җаны сыкрый башлый. Хәтер яраларын еллар җуя алмый шул...

***Рөстәм Гәрәйханов,***
***Мөслим гимназиясенең 7 нче б сыйныфы укучысы***

**Ленар Хөснетдинов**

Олы Чакмак авылында яшәүче Ленар Хөснетдиновның да хәрби хезмәт еллары әфган иле белән бәйле. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, шоферлар курсында укый. Унсигез яше тулуга, армия сафларына бару өчен кулына повестка ала. Казан, Сызрань, Ашхабад шәһәрләрендә булганнан соң, Теджен шәһәренә барып урнашалар, 6 ай учебкада булалар. Өйрәнүләр җиңел булмый. Солдатлар үзләрен әфган сугышына әзерләүләрен яхшы аңлыйлар. Учебканың соңгы көнендә, хәрбиләрне бер рәткә бастыралар да, "Кемнәр Әфганстанга барырга тели - бер адым алга!" диләр. Ротадагы бөтен солдат берьюлы алга атлый.

- Әфган җиренә килеп эләккәч, тәннәр куырылгандай булды, җанны ниндидер бушлык биләп алды. Эсселеккә, җилнең кайнарлыгына түзә торган түгел. Солдатлар җыелып беткәч, егетләрне роталарга бүлделәр. Мин 100 кешелек ротада рядовой, механик-йөртүче булып, танкта хезмәт иттем, - дип сөйли Ленар Хөснетдинов.

Урнашкан урыннары Каравангах тау итәгендә була. Ерак түгел генә Гельмент елгасы урнашкан. Ләкин елгадан су эчәргә, су коенырга ярамый. Йогышлы авырулар эләктерү куркынычы зур була. Бар тик кайнаган су гына эчәргә ярый, кызу булганлыктан анысы да җитми.

- Землянкаларда 12 шәр солдат яшәдек. Ике кеше тышкы якта землянканы саклый иде. Ашарга, солярка ягып, үзебез пешердек. Сугышчан операцияләргә чыгып киткәндә 15 әр көн йөрелә иде. Ул вакытларда үзебез, таулар арасында землянка ясап, түбәләренә төрле ящиклар ябып яшәдек. Хатлар бик озак йөрде, күп вакыт килеп тә җитә алмый иде, - дип сөйли ул.

Шинданд, Гиришк, Фарахруд арасында күп юллар үтәргә туры аларга. Хәрби бәрелешләр вакытында ике тапкыр танкына ут каба. Беренчесендә дуслары аны көч-хәл белән коткарып калалар. Икенчесендә танктагы дуслары һәлак була, ул берүзе дошманнарга каршы көрәшә. Бу юлы да Ленар абыйга бәхет елмая, күпме авырлыклар, кыенлыклар бәрабәренә ул исән-имин кала. Хәрби тревогалар, постта торгандагы йокысыз төннәре дә күп була аның.

Армиядән кайткач Яр Чаллы шәһәрендә озак еллар шофер булып эшли. Бүгенге көндә Ленар абый Олы Чакмак авылында гомер итә. "Без күргән афәтләр башка кабатланмасын, илләребез тыныч, күкләребез аяз булсын",- дип тели ветеран әфганчы.

*Рания Садриева,*
*Мөслим гимназиясенең 7 нче б сыйныфы укучысы*